| СОВЕТ СРЕДНЕКУШКЕТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРТА КӨШКӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«14» март 2023 ел № 68

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Урта Көшкәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнар арасында сораштыру билгеләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль законга туры китереп, һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Урта Көшкәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлеге Советы карар бирде:

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлеге Советының 2012 елның 14 ноябрендә 65 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Урта Көшкәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнар арасында сораштыру билгеләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5.7 пунктта:

- 1 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.7. Гражданнар арасында сораштыру уздыру өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге муниципаль берәмлекнең рәсми сайтын файдаланырга мөмкин. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлеге Советының гражданнар арасында сораштыру билгеләү турында карарында түбәндәгеләр билгеләнә:»;

- түбәндәге эчтәлекле 6 пунктча өстәргә:

«6) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтыннан файдаланып гражданнар арасында сораштыру уздырган очракта, сораштыруда катнашучыларны тәңгәлләштерү (идентификацияләү) тәртибе.»;

1.2. 17.1 пунктның 2 абзацына «яисә муниципаль берәмлек халкы» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет-ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Урта Көшкәт авыл җирлеге башлыгы Перфилов Ю.М.